РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» декабря 2023г. г. Альметьевск №135

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-сәламәтләндерү җирлекләре һәм курортлар турында» 1995 елның 23 февралендәге 26-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 28 февралендәге 63 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

а) 3 пунктның 12 нче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

б) 20 пунктта «шәһәр территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

в) 35 пунктның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, күчемсез милек объектларына хокукларны исәпкә алу һәм теркәүне оештыру, шулай ук нотариусларга архивларда һәм (яки) мондый органнар, оешмалар яки нотариуслар карамагында булырга мөмкин булган элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләре турында мәгълүмат алу максатында запрос җибәрү; »

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә, 2024 елның 01 мартыннан гамәлгә кергән әлеге карарның 1.1. пункты «а» пунктчасы, һәм 2024 елның 01 сентябреннән гамәлгә кергән әлеге карарның 1.1. пункты «б» пунктчасыннан тыш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов